БҮГЕННӘН КАЙГЫРТАСЫ
Кырга чыгарга иртәрәк булса да, орлык һәм транспорт мәшәкате хәзердән үк башлана
> 2



ВАТАН ХАКЫНА
«Бердәм булу көч бирә!»
> 3

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Ялгыз яшәгән әти-әниләрегезнең хәлен белешергә онытмагыз!»
> 4

КЕЧКЕНӘ МИКРОФОН
Иң сәләтле малай-кызларга «Балалар премиясе»н тапшырдылар
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 26 (28993) | Сишәмбе | 21 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

КЕШЕ БУЛСЫННАР!

ТӘРБИЯ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ КИҢӘШЧЕЛӘРГӘ НИНДИ ӨМЕТЛӘР БАГЛЫЙЛАР?

Киләсе уку елында барлык мәктәпләрдә директорның тәрбия эшләре буенча киңәшчеләре барлыкка киләчәк. Узган ел Президент Владимир Путин йөкләмәсе нигезендә «Патриотик тәрбия» федераль проект кысасында илнең 35 төбәгендә 17 меңнән артык шундый белгеч эшли башлады инде. Киңәшчеләр мәктәпне кайсы якка таба үзгәртергә җыена? «ВТ» хәбәрчесе белгечләрнең фикерен белеште.

Безнең мәктәпләрдә болай да тәрбия эшләре буенча урынбасарлар бар бит инде. Бу яңа белгечләр тагын нигә кирәк? Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов белдергәнчә, киңәшчеләр тәрбия өчен җавап бирүдән тыш, балалар иҗтимагый оешмалары белән дә хезмәттәшлек итәчәк. Кыскасы, киңәшче тәрбия буенча эш программасы булдырачак. Укучыларны төрле проектлар белән кызыксындырачак, иҗади, туристик, спорт чаралары оештырырга ярдәм итәчәк. Әйтик, балаларны музей, кино, театрларга йөртәчәк. Эшләре шундыйрак. Киңәшчеләргә федераль казнадан өстәмә акча түләнә.

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин республикакүләм әти-әниләр җыелышларының берсендә әлеге яңалыкка карата үз фикерен җиткергән иде. «Имтихан күрсәткечләре артыннан куып, тәрбияне онытырга ярамый. Бала бик акыллы, әмма тәрбиясез булырга мөмкин. Моннан да куркынычрак әйбер юк», – дигән иде ул.

Мәктәпләрдә бүген болай да спорт, иҗат һәм башка бәйгеләр күп уза. Йөгертәләр һәм сикертәләр, җырлаталар һәм биетәләр, тәрбиягә урын аз бирелә. Кайбер белгечләрдән шундый фикерләр ишетергә туры килә. Бу киңәшчеләр элеккеге «пионервожатый» ролен үтәр дип көтүчеләр дә бар. Әйтик, Арча педагогика көллиятендә мондый киңәшче узган ел эшли башлаган икән инде.

– Мәктәпнең тәрбия юнәлешендәге вазыйфалары бик күп. Тәрбия эшләре буенча урынбасар, педагог-оештыручы, сыйныф җитәкчесе генә куелган барлык бурычларны тиешенчә башкарып чыга алмый. Алар бит тәрбия белән генә шөгыльләнми, дәрес тә укыта. Минем өчен әхлак мәсьәләсе укуга караганда беренче урында. Барлык бала да «5ле»гә генә укып та, юрист та, икътисадчы да булып бетә алмый. Начар укыса да, иң беренче чиратта, кеше булсын. Менә хәзер «Алдынгылар хәрәкәте» булдырылды. Аны оештырырга кирәк. Балалар белән эшләү җиңел түгел. Бүген укытучының болай да эше күп. Бу юнәлешкә ниндидер нәтиҗә ясый торган белгеч булу бик яхшы. Ир-ат укытучы булса, тагын да әйбәтрәк. Балаларга ир тәрбиясе дә җитми, – ди әлеге уку йорты директоры Гөлнара Гарипова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле, мондый штат булдыруны мәктәпләрдә күптән көтәләр. Спас районының мәгариф бүлеге башлыгы Александр Ермилин әйтүенчә, киңәшчеләр зур мәктәпләргә каралган. Әгәр авылда 15 бала гына укыса, андый белгеч билгеләп булмый.

– Болгар шәһәрендә ике мәктәптә булдырылыр дип планлаштырыла. Аларда 500–600 укучы белем ала. Бу бигрәк тә шәһәр мәктәпләре өчен кирәк дип уйлыйм. Сыйныф җитәкчесе бөтенесен күреп, карап бетерә алмый. Бүген ватанпәрвәрләр тәрбияләүгә дә игътибар артты. Эш күп булачак, – диде Александр Ермилин.

«Балалар оешмалары» советы, Казандагы «Подросток» үзәге директоры Екатерина Согрина да бу тәкъдимне хуплый. Тик иң элек кадрларны өйрәтү, мәктәпкә бу эшнең барлык нечкәлекләрен белгән белгечләрнең килүе кирәк.

– Алар тәрбия эшләре буенча урынбасарларны кабатламасын иде. Әгәр киңәшчеләр вазыйфасына үсмерләр клублары белән хезмәттәшлек итү дә керсә, эш тагын да көчәячәк. Мәктәпне тәмамлагач, үсмерләр безгә, төрле клубларга шөгыльләнергә килә. Киңәшчеләрнең яшьләр сәясәтен үстерергә ярдәм итүе дә мөһим, – диде ул.

Егетләр генә укыган мәктәптә дә, кирәкми, димәделәр. Казандагы 7 нче лицей-интернатның директоры урынбасары Алмаз Мансуров фикеренчә, балаларны сәнгать, әдәбият, мәдәният ягыннан да үстерергә кирәк.

– Мәктәпләрдә бу эш алып барыла. Ләкин балалар өчен кызык булган нәрсәләрне, аларның яшь үзенчәлегенә туры китереп, өйрәнеп оештыру файдалы. Шулай иткәндә бу вазыйфа файдалы булыр дип уйлыйм, – ди Алмаз Мансуров.

Азнакай районында яшәүче Алсу Габделхакова заманында укытучы, пионервожатый булып эшләгән. Шуңа күрә мондый белгечләр хисап тутыручы түгел, чын практиклар булырга тиеш дип саный:

– Берәүгә дә сер түгел, хисап югарыдан кушыла. Өлгерәләрме, юкмы, мәктәпләрдә тиз генә нәрсәдер эшләп куялар инде. Аның җиткәнен, җитмәгәнен берәү дә тикшерми. Бер мәктәп белән даими аралашып торам. Укытучыларның вакыты юк. Урамны чыкканда телефонына карап барган бала кебек хәлгә калды алар. Тизрәк мәгълүмат бирәселәре бар. Сыйфат, практик ягы җитми дип уйлыйм. Бардың, кайттың түгел. Барып нәрсә күрдең? Нәтиҗәсе бармы? Җыр-бию бездә күп инде, һөнәргә, тәрбиягә өйрәтү кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

Уеннарга – миллиардлар

«Киләчәк уеннары» ярышларына әзерлек һәм аны уздыру өчен федераль бюджеттан 5,2 млрд сум акча тотылачак. Бу хакта Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин хәбәр итте.

Уеннарга тотылачак сумманың бер өлеше, ягъни 1,8 млрд сум – 2023 елда, калган 3,5 млрд сум 2024 елда бүлеп биреләчәк.

Вице-премьер Дмитрий Чернышенко аңлатканча, Уеннарга әзерлек белән оештыру комитеты шөгыльләнә. Аңа футбол буенча дөнья чемпионатына, Универсиада һәм башка зур чараларны оештыруда катнашкан вәкилләр дә керә, дип билгеләп үтте ул.

Билгеле булганча, «Киләчәк уеннары» халыкара киберспорт турниры Казанда 2024 елда узачак. Ярышлар 23 февраль – 2 март көннәрендә үтәр дип көтелә. Халыкара турнирда 16 төрле юнәлеш буенча 256 команда көч сынашачак. Спортчыларга виртуаль дөньяда һәм чынбарлыкта осталык күрсәтергә туры киләчәк.

Чит итмиләр

Мәскәү, Ленинград өлкәләре һәм Санкт-Петербург – чит илләрдән килеп эшләүчеләр өчен иң кызыктыргыч төбәкләр. Finexpertiza аудиторлык челтәре хезмәте үткәргән тикшеренү нәтиҗәләре шундый. Алардан күренгәнчә, узган елда барлыгы 11,8 миллион чит ил кешесе исәпкә алынган. 40 процентыннан күбрәге – Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенә туры килә. Чит кыйтгалардан килгән эшче кулларның 12,8 проценты Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендә теркәлгән. Хезмәт мигрантлары үз иткән төбәкләр арасына Краснодар крае, Иркутск, Свердловск өлкәләре, Татарстан (мигрантларның 1,6 проценты яки 192 мең кеше) да кергән. Өчтән бер өлеше Россиянең башка төбәкләрен сайлаган.

Торак алучылар кими

Гыйнвар аенда Татарстанда барлыгы 5,7 мең кеше торак сатып алган. Шул ук вакытта узган елның декабрендә 7,3 мең алыш-биреш теркәлгән булган. Ягъни торак сатып алучылар 21,6 процентка кимегән.

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, иң күп килешүләр Казанда төзелгән (1,9 мең). Республикада ипотека буенча (җир кишәрлекләрен дә кертеп) барлыгы 2,3 мең килешү имзаланган. 5,9 мең торак ипотекага сатып алынган. Узган айда җир кишәрлеген сату-алу буенча 5,2 мең алыш-биреш теркәлгән. 1000нән артыграгы – Казанда.

2022 елда республикада торак сатып алучылар 38,8 процентка кимеп, 101585 килешү төзелгән (2021 елда – 166021). Декабрь аенда күчемсез милек базары барыбер элекке хәленә кайта алмаган: нибары 7311 сату-алу килешүе теркәлгән. Шул ук вакытта 2021 елның декабрендә мондый алыш-бирешләр саны 2,7 тапкыр күбрәк булган (19376 килешү).

Агуланганнар

Узган елда Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе көнкүрештә «химия» белән агулануның 2748 очрагын теркәгән. Соңгы биш ел эчендә бу күрсәткеч 1,6 процентка арткан, шулай да 2021 елдагы белән чагыштырганда 1,7 процентка кимегән.

2022 елда агулануларның күпчелеге (40,7 проценты) очраклы килеп чыккан. 25,7 процентының сәбәбе – исерү, шулай ук үз-үзенә кул салырга теләү. 33,6 проценты башка сәбәпләргә бәйле.

Белгечләр ачыклаганча, ир-атлар ешрак агулана (64,7%). Хатын-кызлар арасында мондый очраклар 1,8 тапкыр кимрәк теркәлгән. Күңелсез очракларның 35,2 проценты – химик матдәләргә, 22,8 проценты – дару, 22,5 проценты – хәмер һәм башка спиртлы эчемлекләргә, 19,5 проценты наркотик матдәләр белән агулануга туры килә.

Агуланудан үлем-китем күрсәткече 100 мең кешегә 15,3 күрсәткечен тәшкил иткән (алдагы елдагыга караганда 15,5 процентка кимрәк). 2018 елдагы белән чагыштырганда 1,3 тапкыр үсеш күзәтелә. Үлем-китемнәрнең төп өлеше үсмерләр арасында теркәлә.

Яңалык

Шаһитларсыз да узачак

1 марттан Россиядә машина йөртүчеләрне исерткеч эчемлек куллануга тикшерүнең яңа кагыйдәләре үз көченә керә. Аерым алганда, хәзер мондый тикшерүләрне ике шаһит булганда гына түгел, видеотеркәү ярдәмендә дә үткәрергә мөмкин.

Әлегә кадәр «тимер ат» ияләрен хәмергә тикшерүнең 2008 елда кабул ителгән кагыйдәләре гамәлдә иде. Яз башыннан үз көченә керүче яңа документ бу өлкәгә берничә яңалык кертә. Машина йөртүченең авызыннан исерткеч эчемлек исе килсә, үз-үзен тотышында, сөйләмендә хилафлыклар сизелсә, бу аны тикшерү өчен нигез булырга мөмкин. Бу очракта инспектор иң элек әлеге җиһазның келәймәсе төзек икәнлекне күрсәтергә тиеш. Машина йөртүче аннан алкотестерның техник документларын да сорарга хокуклы. Мартның беренче көненнән үз көченә кергән үзгәрешләр нигезендә инспекторга моны эшләү мәҗбүри булмаячак. «Тимер ат» иясенә алкотестер турындагы тулы мәгълүматны Үлчәүләр берлеген тәэмин итү буенча федераль мәгълүмат фонды аша үзенә табарга туры киләчәк.

Билгеле булганча, машина йөртүчене алкотестер ярдәмендә тикшерү ике шаһит катнашында башкарыла. Әмма яңа үзгәрешләр нигезендә, инспектор бу эшне видеотеркәгеч ярдәмендә яздырып барса, аларның ярдәме таләп ителмәячәк. Дөрес, машина йөртүчеләрне көпшәгә өрдереп тикшерүне видеоязмага теркәп бару мөмкинлеге Административ хокук бозулар турында Россия кодексында да теркәлгән. Әмма гамәлдә ул сирәк кулланылды. Яңа кагыйдәләр нигезендә бу мөмкинлекне дә популярлаштырырга җыеналар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Автомобиль ияләре федерациясенең Татарстандагы вәкиле Рамил Хәйруллин машина йөртүчеләрне алкотестер ярдәмендә тикшерүне видеога теркәп бару мөмкинлеген күпкә нәтиҗәлерәк алым дип саный.

– Ахырдан бу видеоязманы машина йөртүченең үзенә дә тапшырырга кирәк. Ул ике арада бәхәс туган очракта бик яхшы дәлил дә булачак. Шаһитлар урында күп нәрсәне күреп, аңлап та бетермәгән булырга мөмкин бит. Видеоязмада барысы да минуты-секундына кадәр теркәлгән булачак, – ди белгеч.

Россия Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, исерек машина йөртүчеләр катнашындагы иң күп юл фаҗигаләре май аенда, җәй көне, шимбә-якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә теркәлә. Юл һәлакәтләренең күбесе кичке сәгать биш белән төнге сәгать унике арасында килеп чыга, ди белгечләр. Исерек килеш рульгә утыручыларның 94 процентын ир-атлар тәшкил итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Евгений ВАРАКИН, Татарстан Премьер-министры урынбасары:

Җиде айдан бирле Лисичанскида даими эшлибез. Фронт линиясе бездән 10–15 чакрымга читтәрәк булса да, без әле дә сугышның алгы сызыгында. Башта монда ни дә булса эшли алуыбызга беркем дә ышанмады. Бүген шәһәр 100 процентка газлаштырылды, халкының 25 процентына су тоташтырдык инде.

(«Татар-информ»дагы әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – COVID-19

стопкоронавирус.рф сайты мәгълүматлары буенча, Россиядә соңгы тәүлектә 12076 авыру очрагы теркәлгән.

Төбәк	Хастаханәгә салынган	Сәламәтләнгән	Ачыкланган
Мәскәү	108	1830	1940
Санкт-Петербург	68	681	1412
Мәскәү өлкәсе	25	189	191
...			
Башкортстан	4	268	278
...			
Калининград	1	217	195
Татарстан	**18**	**98**	**145**
...			
Чукотка	0	1	1

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ИМИНЛЕК ОЧРАШУЫНДА СУГЫШ ТУРЫНДА

Үткән атнаның төп халыкара вакыйгасы Иминлек буенча Мюнхен конференциясе булды. Европада куркынычсызлык темасын үзәккә алган бу очрашу быел, аңлашыла инде, Россиягә каршы контекстта үтте. Конференцияне видеоэлемтә аша Украина Президенты Владимир Зеленский ачып җибәрүе, Украина делегациясенең сан ягыннан АКШ делегациясеннән кала икенче урынны алып торуы Мюнхен җыелышының кон тәртибендә ни торуын бик ачык күрсәтте.

Конференциядә катнашучылар санын чакырулы як, ягъни Германия билгели. Озак еллар буе Россия белән аркадашлык иткән, Себер газын иң күп ягучы немецлар бер ел эчендә позицияләрен кискен үзгәртте һәм Кремльгә каршы позага бастылар. Илнең оборона министры Борис Писториусның «Bild» газетасына биргән интервьюсында: «Дөнья Путиннан башка яхшырак булыр иде», – дип белдерүе, тышкы эшләр министры Бербокның: «Россия үз сәясәтен үзгәртеп, 360 градуска борылса, дөнья бик бәхетле булыр иде», – дип кеше көлдерүе (360 градуска борылу шул ук ноктага кабат әйләнеп кайту бит инде) конференция хуҗаларының Украина конфликтында төп гаепне Кремльгә өстенә аударуларын турында сөйли.

Шуңа күрә конференциядә төп тема Украинаны коралландыру булды. Искә төшерик әле: Британия Премьер-министры Лиз Трасснын 45 көн дә идарә итә алмыйча отставкага китүенә Кремльдә Дмитрий Медведев теле белән ничек сөенгәннәр иде. Аның урынына килгән Риши Сунак Мюнхен мөнбәреннән торып Украинага хәрби ярдәмне 2022 елдагыга караганда ике тапкыр арттырачакларын һәм еракка оча торган ракеталар бирәчәкләрен игълан итте. Башка Көнбатыш дәүләтләре дә ярдәмне көчәйтү ягын куәтли. Немецларның PzH 2000 үзйөрешле артиллерия җайланмаларын кулланырга өйрәнгән хәрбиләр төркеме якын көннәрдә Германиядән Украинага кайтып төшәчәк икән. PzH 2000 – иң яхшы артиллерия җайланмаларыннан санала. Гадәти снарядлар белән – 36, актив-реактив снарядлар белән 67 километрга кадәр ата. Шул ук Германия полигонында M2 Bradley машиналарында сугышырга өйрәнгән 635 украин хәрбие дә илләренә кайтырга әзерләнә. M2 Bradley пехота машиналары идарә ителешле TOW танкка каршы ракеталар белән коралланган, шуңа күрә алары танк юк итүче машиналар дип тә йөртәләр. Американнар 150 километрга атучы GLSDB ракеталарын вәгъдә итә. Болары санаулы минутлар эчендә калканлы техника колонналарын еракта торып юк итәргә сәләтле.

Мюнхенда киеренкелекне йомшартырга, якларны сөйләшүләр өстәле янына утыртырга чакырулар да булды. Кытай делегациясен җитәкләгән Ван И, мәсәлән, февраль ахырына конфликтны сөйләшүләр юлы белән көйләү планын тәкъдим итачәген белдерде. Бразилия Президенты Лула да Силва да Россия белән сөйләшүләр алып бару өчен «тынычк клуб» төзү яклы. Венгрия Премьеры Виктор Орбан Мәскәү белән Вашингтон сөйләшүләрен оештырырга чакыра. Путин белән телефоннан сөйләшүләр буенча рекорд куйган Макрон исә: «Россия сугыш кырында җиңелергә тиеш, әмма аны, кайберәүләр теләгәнчә, җимерелүк ташларга ярамый», – дигән тезисны алга сөрде. Нәрсә генә булмасын, вәза конференциясы көчәер төсле. Көнбатыш лидерлары Киевны контрһөҗүм башларга өнди.

Россиядә

ТАБАРГА ТУРЫ КИЛӘЧӘК

Украинага Көнбатыш дистәләгән миллиард долларлык ярдәм оештырганда, Россия бюджеты керемнәре белән чыгымнарын чагыштыра алмый. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе үткән атнада Россиянең аек акыллы икътисадчыларынан белеште: бюджет дефициты зур булса да, резервларны ел-ел ярымга сузып була икән әле. Милли байлык фондын кабартуның бер чарасы күрелә инде: валюталар рус сумына карата нык ыгылар. Аларның кыйммәтләнүе саклык акчаның сумнардагы күләмен үстерә. Акрын гына дефициты халык җилкәсенә күчерәләр. Акча барыбер җитми, чөнки Россия сата торган чималларга бәя төшә. Газ бәясе җиде тапкыр түбәнәйде, диделәр.

Үткән атнада федераль хөкүмәт һәм Дәүләт Думасы бар вакытларын диярлек акча табуга исраф иттеләр: нефтьчеләргә салымны яңадан карау белән мәшгуль булдылар, бизнесның бюджетка «ирекле» һәм бик үк ирекле булмаган взнослар түләвенә ирешүен кайгырттылар. Россия Президенты Владимир Путин сүзчесе Дмитрий Песков: «Анда төп сүз «ирекле», – дип аңлатса да, финанс министры Силуанов әфәнде бюджетка өстәмә взнослар җыю мәсьәләсенең кабыргасы белән куелачагын аңлатты. Былтыр 200–250 миллиард сум акча җыю турында сүз чыгарсалар, министрлыкта хәзер әзеп әйтәләр: үткән ел табышы бер миллиард сумга җиткән һәм аннан арткан һәр бизнесмен взнос түләячәк һәм җыелган сумма 300 миллиардтан да ким булмаячак. Телеграм-каналларда, ирекле взнослар өч тапкыр җыелачак, ел ахырына миллиардерлардан 1 триллион сумга кадәр акча савачаклар, дигән сүзләр дә йөри.

«Ирекле» взнослар белән генә бар тишекләрне дә каплап бетереп булмас. Нефть-газ тармагыннан өстәмә керемнәр каерып алу да тормышка ашырыла. Салым формулалары үзгәртелә. Файдалы казылмалар салымын үзгәртү өстәмә 575 миллиард сумга кетәләр, ягулык демпферы белән уйнап, 85 миллиард сум тапмакчылар. Бу соңгысы бензин бәясен күтәрмәсме – әле төгәл билгеле түгел.

Европада газга бәяләр төшә, безда күтәрелер, мөгаен. Чәршәмбе көнне Думаның Энергетика буенча комитеты экспорт югалтуларын эчке базарда газга бәя күтәреп компенсацияләргә тәкъдим итте. Әлегә сүз бәяне сәнагать кулланучылары өчен генә күтәрү турында бара.

ХӘРБИ КҮРГӘЗМӘДӘ

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Абу-Дабида IDEX – 2023 халыкара күргәзмәсе ачылышында булды. Татарстан компанияләре әлеге күргәзмәдә 1995 елдан бирле катнаша. Рөстәм Миңнеханов республика компанияләре тәкъдим иткән продукция белән танышканнан соң, Россия вертолетлары стендын да карады.

Утызынчы юбилей күргәзмәсендә Россия павильонында «Рособоронэкспорт» акционерлык җәмгыяте, «Алмаз-Антей» концерны, «НПО «Высокоточные комплексы» акционерлык җәмгыяте, «Технодинамика» акционерлык җәмгыяте, «Швабе-Медиа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «ОПК» акционерлык җәмгыяте, Ульяновск патрон заводы, ФПК «Казанский ГКПЗ» оешмасы тәкъдим ителде.

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – республиканың төп сәүдә-икътисадый хезмәттәшләренең берсе. Республика ике арадагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга зур өлеш кертә. Узган елның тугыз ае нәтиҗәләре буенча Татарстан белән Берләшкән Гарәп Әмирлекләре арасында товар әйләнеше 5 тапкыр диярлек артып, 28,6 млн доллар тәшкил иткән.

Халыкара күргәзмә барышында Рөстәм Миңнеханов Төркиянең төрле авиация эшләнмәләре тәкъдим ителгән күргәзмәдә дә булды. Очрашуда Төркия вәкилләре Казан вертолет заводы белән хезмәттәшлек итәргә кызыксынуларын белдерде. Рөстәм Миңнеханов исә компания вәкилләрен республиканың сәнәгать мөмкинлекләре белән танышу өчен «Kazan Forum»га чакырды.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов «Tawazun» павильонында да булды. Алабуга шәһәрендә автомобильләр җитештерү буенча АУРУС проектының 36 проценты әлеге холдингныкы санала. Компания оборона җитештерүләрен бер урында туплау өчен төзелгән сәнәгать паркын тәкъдим итә. Проектның асылы мондый типтагы предприятиеләр ачу өчен инфраструктура һәм барлык кирәкле шартлар тудырудан гыйбарәт.

ЭШЛӘП АШАРГА

2022 ел нәтиҗәләре буенча Россиядә эшсезлек дәрәҗәсе 30 процентка кимегән. Бу хакта Россия вице-премьеры Татьяна Голикова хезмәт базарын торгызу буенча ведомствоара эшче төркем утырышы барышында хәбәр итте. Мәшгульлек, хезмәт базарында хәлләр тотрыклы, дигән түрә. Саннар ни сөйли соң?



Идар Мөхәммәтҗанов

2022 ел азагына рәсми рәвештә теркәлгән эшсезләр саны 564 мең кешене тәшкил иткән. Чагыштыру өчен: 2021 ел азагында аңнардыйлар саны 777 мең булган! Гомумән, мәшгульлек үзәкләренә ел дәвамында төрле сораулар белән 3,2 млн россияле мөрәҗәгать иткән.

2022 елда эш эзләүгә сарыф ителгән уртача вакыт күрсәткече арткан. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Һәр хезмәт тә күңелгә ятышлы була алмый бит. Эшнең матди ягы да кызыксындыра. Шулай итеп, эш табу өчен уртача 4,6 айга кадәр вакыт кирәк икән (2021 елда – 4,3 ай). Консультантлар, махсус кешеләр аша эш эзләү вакытны азрак сарыф итәргә мөмкинлек бирә. Анысына уртача 3,5 ай китә икән.

Татьяна Голикова сүзләренә караганда, узган ел Россиянең 13 төбәгендә эшсезлек дәрәҗәсе арткан. Алтай, Хакасия, Санкт-Петербург, Ленинград һәм Кемерово өлкәләре аеруча. Тагын 68 төбәктә күрсәткечләр кимегән, дүртесендә үзгәрешсез калган.

Рәсми рәвештә теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,7 процентны тәшкил итә. Россия җитәкчелеге ел дәвамында хезмәт базарындагы вазгыять сизелерлек үзгәрмәс дип ышанды. «Эшсезлек күрсәткече үсеше өчен нигездәр алшартлар күрмибез. 2023 елда да эшсезлек дәрәҗәсе түбән булачак», – ди Россиянең икътисадый үсеш министры урынбасары Полина Крючкова.

КАЙДА КҮПМЕ?

2022 ел нәтиҗәләре буенча, иң түбән эшсезлек күрсәткече Чехиядә теркәлгән. Иң авыр вазгыять – Испаниядә. «РИА Новости» агентлыгы эшсезлек дәрәҗәсе буенча Европа илләре рейтингын тәкъдим итә.

Урын	Ил	%
1	Чехия	2,3
2	Германия	2,8
3	Польша	2,9
...		
10	**Россия**	**3,7**
...		
31	Италия	8,0
32	Греция	11,8
33	Испания	12,9

Эше булып та, эшләргә кеше булмаган тармаклар да юк түгел. Үзәк банк мәгълүматларына ышансаң, кадрлар кытлыгы машина төзелеше, металлургия, төзелеш һәм транспорт тармакларында аеруча сизелә. IT тармак белгечләре турында кабатлап әйтәсе дә юк.

Хәзерге вакытта Россиядә эшкә яраклы халык саны кимүен дәвам итә. Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2022 елның декабренә 15 һәм аннан да өлкәнрәк яшьтәге эшче куллар саны 74,9 млн кешене тәшкил итә, а бер ел элек бу сан 75,7 млн булган. Барлы-юклы бер ел эчендә генә дә хезмәткә яраклы булырлык 800 мең кешене югалткапбыз дигән сүз. Саннарның җитдилеген тагын бер чагыштыру дәлилләр: 2017 елда потенциаль эшче куллар саны 76,3 млн кеше булган!

ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары Ассамблеясы Советы Рәисе ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИНның Халыкара туган тел көне уңаеннан котлавы

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне 21 февральда Җир шарының барлык тарафларында да билгеләп үтелә торган Халыкара туган тел көне белән котлыйм. Бу истәлекле дата безгә дөнья халыкларының туган телләрен ихтирам итү, «җанлы» матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм үстерү зарурлыгын тагын бер мәртәбә искә төшерә.

Гасырлар дәвамында күпмиллә тле һәм күпконфессияле дәүләт булараклар формалашкан Россия өчен туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсе гаять зур әһәмияткә ия. Ул күп гасыр бәхәсләр тудыра, һәрьяклап уйланган һәм эзлекле чишелеше таләп итә. Бөек илебезнең иксез-чиксез киңлекләрендә йөзләгән халыкларның язмышы бергә үрелгән, узара дустанә яшәүнең һәм төрле милли мәдәниятләр кушылуның уникаль тәҗрибәсе булдырылган. Россия дәүләтенең яңартылган Төп законында мәдәният һәм тел күптөрлелеген гарантияли торган нормаларның беркетелүе дә бик тә табигый күренеш.

Татарстан – иң алдынгы Россия Федерациясе субъектларының берсе, монда 170тән артык халык вәкилләре яши. Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт Советына еллык Юлламасында мондый юллар бар: «Туган тел, туган җир, рухи-әхлакый традицияләребез, бай тарихи-мәдәни мирасыбыз, милләтара һәм динара татулык һәм тыныччлык – болар барысы да бездә горурлык хисе тудыра, аерым игътибар һәм әһәмият бирелә торган кыйммәтләр булып тора һәм киләчәктә дә, һичшиксез, шулай булачак». Шушы төп нигезләрне саклауга һәм ныгытуга зур әһәмият бирер, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасы елының дәвамы буларак, 2023 ел республикабызда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Һичшиксез, аның кысасындагы чаралар җәмгыятьтә толерантлык идеяләрен ныгытуда, кече һәм олы Ватанга карата мәхәббәт тәрбияләүдә тагын бер адым булачак. Гражданлыкның формалаштыруга һәм яшьләрдә ата-бабаларыбызның мәдәниятенә белән кызыксынуны уятуга этәргеч ясаячак. Халыкара туган тел көне төрле телләрдә сөйләшүче кешеләрнең үзара аңлашуын алга таба да ныгытсын, бер-берәнне яхшырак белергә, балаларга һәм оныкларга туган телгә мәхәббәтне һәм Ватан өчен горурлыкны тапшырырга ярдәм итсен. Барыгызга да ихлас күңелдән нык сәламәтлек, тынычлык, бәхет һәм иминлек телим!

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык беренче утырышы 22 февраль көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 22 февральда 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

КҮРШЕНЕКЕ ЯХШЫРАК

Язны көткәндә

Басуларда техника гөрелтесе ишетелергә иртәрәк булса да, орлык һәм транспортны әзерләү мәшәкатьләре инде тулы куәткә бара. Алай гына да түгел, бүген республика буенча язгы бөртекле культура орлыклары белән тәэмин ителеш 125 процентны тәшкил итә. Шул ук вакытта республика хуҗалыклары техник культуралар (көнбагыш, шикәр чөгендере) һәм кукуруз буенча импорттан кергән орлыкларга бәйле.

Идар Мөхәммәтҗанов

Тулаем республика буенча 24 процент чит ил кукуруз гибридлары, 99 процент шикәр чөгендере һәм 72 процент көнбагыш чәчелә. Бу хакта Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә хәбәр итте.

Министр сүзләренчә, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы читтән кертелә торган орлыкларның контракт буенча атналык мониторингын алып бара. Марат Җәббаров инвесторлар һәм хуҗалык җитәкчеләренә сатып алынган орлыклар белән тәэмин итү килешүләренең актуальлеген тикшерергә кушты. Быелга иң мөһим бурычларның берсе – чит ил сортлары һәм гибридларын сайлау. 2024 елдан Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы чит илдән кертелүче көнбагыш, шикәр чөгендере, кукуруз, рапс орлыклары һәм орлыклык бәрәңге алуга квоталар урнаштырырга планлаштыра.

Билгеле булганча, быелгы уңыш өчен көзге культуралар 472 мең га мәйданда чәчелгән, шулардан көзге бодай – 378 мең гектарда, көзге арыш – 89 мең гектарда. Шул ук вакытта көзге культураларның 40 проценты оригиналь һәм элиталы орлыклар белән чәчелгән.

– Әлегә уҗым культуралары буенча авырлык юк. Авыл хуҗалыгы үзәгенең Татарстан филиалы көзге уҗымнарның кышлавын атна саен тикшереп, күзәтеп тора. Әлеге нәтиҗәләрдән күренгәнчә, уҗымнарның 96 проценты – яхшы хәлдә, 23 проценты – канәгатьләнерлек, – диде Марат Җәббаров.

Билгеле сәбәпләр аркасында, узган ел хуҗалыклар: «Быелга орлыкларны алып өлгердек. Киләсе ел күркыта», – дигән иде. Бу уңайдан көнбагыш, шикәр чөгендерен күпләп үстерүче Зәй районына шалтыратырга булдык. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Фәргать Камалиев шикаятьлебеянча, авырлык быел да булырга тиеш түгел.

– Безнен районда шикәр заводы булганга, бу мәсьәлә белән «Агросила» агрофирмасы шөгыльләнә, – диде ул. – Безнең инде барлык төр орлыклар өчен – иртә һәм соң өлгерә торганнар – контракт төзелгән, акча түләнгән, алып кына кайтасы булачак. Көнбагыш, шикәр чөгендере орлыклары өчен дә исәп-хисап ясалган, проблемалар булыр, дип уйламыйм. Орлыклар чит илдән кертелә. Тик киләсе еллардан үзебездә дә эшли башлаячаклар, дигән сүзләр йөри. Билгеле, бу тиз генә эшләнә торган эш түгел.

Шулай да үзебездә орлыклар җитештерү буенча вазгыять ничек соң? Соңгы елларда алга китеш бармы?

– Селекция буенча эшлисе эшләр бик күп әле, а менә узган елдан башлап безнең җәмгыятькә эре хуҗалыклар тарафыннан игътибар артты, – ди Кукмара районының «Тойма» җәмгыяте баш агрономы Мөнир Галимҗанов.

Әлеге оешма элиталы орлыклар үстерү белән шөгыльләнә. Алар тәҗрибә мәйданнарында орлыкларны үстереп карап, безнең территориягә иң уңышлы туры килә торганнарын сайлап ала.

– Узган елга кадәр күпчелек очракта фермерлар, вак хуҗалыклар белән эшлидек, санкцияләр кертелгәч, махсус хәрби операция башлангач, зур компанияләрнең дә игътибары артты. Моңа кадәр дә орлык сату белән авырлык булганы юк иде, хәзер заказларның күләме тагын да артты. Күрәсең, чит ил орлыкларын үзебезнекеләргә алыштыручылар күбәйгәндер, – диде ул.

Шулай да, Мөнир Галимҗанов фикеренчә, безнең илдә җитештерелгән сортларның төрлелеге һәм сыйфатлары буенча чит илнекеләрдән күпкә калышабыз.

– Без институтлар белән эшлибез. Алардан оригиналь сиәмнәр алып, үрчетеп, билгеле бер максатларда кулланыр өчен уңышлыларын сайлап алып сатабыз, – ди ул. – Дөресен әйткәндә, сыйфат аксый әле. Сортлар аз. Бу мәсьәләдә эшлисе эшләр күп. Яңа сортлар кирәк. Чит илнекеләр уңышны яхшырак бирә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН АВАЗЫ

МОННАН 10 ЕЛ ЭЛЕК 21 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ТАТАРСТАН ГИМНЫ БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР СҮЗЛӘРЕ БЕЛӘН ЯҢГЫРАДЫ

Тарих

Гимн сүзләренең авторы, шагыйрь Рамазан ага Байтимеровның кызы Гөлшат ханым апрель аенда әтисенең 100 еллыгын бәйрәм итәргә җыенып йөри. Шул уңайдан шигырьләрен җыйнап, бәләкәй генә китап та әзерләгән.

Җырга күчкән язмыш

Кызы әйткәнчә, сикәлтәле була Рамазан аганың тормыш юллары. Хәтта бу халәт үзе бакыйлыкка күчкәч тә дәвам итә. Монысы бигрәк тә Татарстан гимнының сүзләренә кагыла. Гөлшат ханым бу хакта менә ниләр сөйли:

– Әтием «Туган ягым» шигырен ТАССРның 50 еллыгына багышлап, 1970 елда иҗат иткән иде. Композитор Рөстәм Яхин аңа көй язды. Аларның бу иҗат җимеше патриотик җырлар бәйгесендә җиңү яулады. Бик тиз популярлык казанды. Профессиональ җырчылар да бик яратып җырладылар аны. Хәтерлим әле, телевизордан яңгыраган вакытта әтием бар көченә кычкыртып тыңлый, безгә сиздермәскә тырышып горурлана иде. Бәйсезлек яулаган Татарстанга гимн кирәк булды. Бәйгенең финалына ике җыр чыкты: Габдулла Тукай сүзләренә татар халык җыры «Тәфтиләү» һәм Рөстәм Яхинның әтием шигыренә язган җыры – «Туган ягым». Ул вакытта гимнны сүзсез генә расладылар.

1993 елда Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев күрсәтмәсе белән республиканың гимнын булдыру һәм кабул итү буенча әзерлек эшләре башлана. Бу максатта Татарстан Югары Советында махсус комиссия оештырыла, аның рәисе итеп депутат Ренат Харис билгеләнә. Республика парламенты гимнга музыка сайлап алу буенча конкурс игълан итә. Ноталар һәм магнитлы язмалар рәвешендә 150 музыкаль әсәр тәкъдим ителә. Беренче этапта 30 проект исәпкә алына. Тавыш бирү нәтиҗәсендә Рөстәм Яхин музыкасын сайлап алалар. Гимнның текстын соңрак кабул итү турында килешенә.

Бервакыт шулай «Парламент сәгате» тапшыруында шагыйрь, депутат Разил Вәлиев: «Гимнга сүзләр барыбер кирәк», – дигән тәкъдим белән чыкты. Гимн сүзләренә конкурс игълан иттеләр. Шул вакытта Татарстан Язучылары берлеге рәисе вазыйфаларын башкарган Илфак Ибраһимов мондый киңәш бирде: «Син архивтан әтиеңнең шигырен эзләп тап та берәр шагыйрьгә эшкәртергә бир», – диде. Мин, тәртипле кеше дип белгәнгә, Гәрәй Рәхимгә тукталдым. Ул үзе дә әтине яхшы белә иде. Ә матбугатта әтиемне беренче булып Туфан Миңнуллин яклап чыкты. Һәм аның сүзләре хак булды.

Яшәү хакына

Әйтергә кирәк, Рамазан ага – бик бәхетле ата. Әгәр кызы аның иҗатын барлап йөрмәсә, гимнның сүзләре үзгәрергә бик мөмкин иде. Күп кенә шигырьләре дә югалыр иде. Гөлшат ханым үз вакытында әтисенең үзе исән чагында дөнья күрә алмаган шигырьләрен барлап, «Яшәү хакына» дип аталган зур булмаган җыентыгын да чыгарды. Гимнны кабул иткәч, 90 еллык юбилеена «Татнефть» «Җырга күчкән язмыш» дип аталган китап чыгарды. Шагыйрьнең иҗаты патриотизм һәм туган якны ярату хисләре белән сугарылган. Күрәсең, изге ай хөрмәтенә Рамазан исеме алган малайның матур табигать кочагында туып үсүе дә, балачактан әтисез калып, чит җирләрдә каңгырап йөрүе дә эзсез калмагандыр.

– Әтием Башкортстанның Авыргазы районындагы Исмәгыйль авылында гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә, – дип хатирәләрен барлый Гөлшат ханым. – Бабам бакыйлыкка бик иртә күчә, әбием алты бала белән кала. Авылда башлангыч сыйныфлар гына булу сәбәпле, әтием күршедәге Ишле авылына йөреп укый. Бик шук була. Җиденче сыйныфтан соң Үзбәкстанга, апасы янына китеп бара. Кәттәкурганда яши, Сәмәркандка йөреп укый. Акча җитмәгәч, вагон түбәсен «үз итә». Аннан Ташкентта укытучылар курсын тәмамлый. Тик эшләргә генә өлгерә алмый кала. 1941 елның көзендә армиягә алына. Мәскәү янындагы укчылар полкына эләгә, һава десантчылары курсларында укый. Парашют белән бер йөз тапкыр сикерергә туры килде бугай, дип сөйли иде. Әтием туган якка 1945 елның ноябрендә генә әйләнеп кайта. Сугыш хакында күп сөйләргә яратмый иде. Күрәсең, җелегенә үткән булгандыр. Ике абыйсы да яу кырында ятып калган.

Фронттан кайткач, Рамазан ага математика укытучысы булып эшли, гаилә кора. Иҗат белән мавыга башлый. Беренче шигырьләре «Кызыл таң» газетасында басыла. 1949 елдан Казан университетының журналистика бүлегендә укый, эшли башлый. 1958 елда Лениногорскига күченеп китә. Газета редакциясендә, телевидениедә эшли. Тик сәламәтлеге какшап китә, 39 яшендә инфаркт кичерә.

Рамазан Байтимеров

ak-bars.ru

Гимн – республикада яшәүче күпмилләтле халыкны берләштерүче көч ул.

Алмагач

– Дүрт сутыйлык бакчага тиенгәч, әтием бөтен барлыгын алмагачлар үстерүгә багышлады, – дип истәлекләрен дәвам итә Гөлшат ханым. – Берничә көн эчендә өй дә әмәлләп куйды. Җиңү көнендә ул митингка чыкмый, бакчага китеп, хатирәләре белән яшәп ала иде. Хәтта кыш көне дә барып, алмагачларның төбен таптап кайтты. Якты дөнья белән хушлашуы да чаңгы белән бакчага йөрергә чыккач, өченче инфарктан соң булды. Әниемә кемдер: «Рамазан абый егылган», – дип шалтыратты. Мин шундук ни булганын аңладым. Әтием соңгы мизгелдә дә солдат булып калган, аягүрә баскан килеш сердәшләре – алмагачлары янында егылып үлгән. Бу 1989 елның 2 феврале иде.

Алмагачка бәйле истәлекләр моның белән генә бетми әле.

– Әтием үләр алдыннан гына өй янында алмагач утырткан иде. Ул үсеп китә алмады, корый башлады. Әмма аны кисәргә беркемнең дә кулы күтәрелмәде. Һәм ни гаҗәп: 2012 елда алмагач чәчәк атты. Мин моны могҗизага юрадым. Ә бит могҗиза чыннан да булды. Озакка сузылган шау-шулардан соң Татарстан гимны сүзләренең авторы итеп аның чын хуҗасын – әтием Рамазан Байтимеровны тәгаенләделәр. Бу минем иң бәхетле көнем иде.

2011 елның декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы Дәүләт гимны тексты проектына иҗади бәйге игълан итә. Комиссия рәисе итеп Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова билгеләнә. Бәйгегә 200дән артык проект тәкъдим ителә. Шулар арасыннан 182 эш конкурста катнашырга лаек дип табыла. Беренче этапта егермеләп проект сайлап алына. Икенче турга Гөлшат Байтимерова җибәргән «Батыр» исемле проект уза. Әмма текстка тантана, гимн бөеклеге җитми торган була. Шуңа күрә дә чираттагы этапта текст шактый үзгәрешләр кичерә. Филипп Пираев гимн сүзләрен рус теленә тәрҗемә итә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Алойл» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры **Вафин** Риф Вәкил улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

«ТВОЙ ДОМ» төзелеш компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең башкарма директоры, «ПРОФИТ» компанияләр төркеме җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары (Чаллы шәһәре) **Бәдыйков** Рубин Әбүзәр улына, «АйСиЭл – КПО ВС» акционер җәмгыяте генераль директорының капиталь төзелеш буенча урынбасары **Бариев** Фидаэль Шакирзян улына, «СТРОЙКОНТАКТЭНЕРГОПЛЮС» ТК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Вәлиәхмәтов** Радик Хәсән улына, «Татарстан Республикасының инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Рәшитова** Светлана Сирень кызына, «Татарстан Республикасының инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе сатып алулар һәм дәүләт контрактларының үтәлешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы **Хаҗиева** Элина Рим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык-физиология бүлекчәсе мөдире – табибы – акушер-гинекологы **Җәлалтдинова** Миләүшә Фәрит кызына, «2 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эндокринология бүлекчәсе мөдире – табиб-эндокринологы (Чаллы шәһәре) **Исхакова** Гүзәл Сәет кызына, «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең бала тудыру йорты гинекология бүлекчәсе мөдире – табибы – акушер-гинекологы **Кәримова** Әлфия Рауил кызына, «2 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми табиблык практикасы бүлекчәсе мөдире – табиб-терапевты (Чаллы шәһәре) **Маллабаева** Ирина Иргаш кызына, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең неврология бүлекчәсе табиб-неврологы **Стаценко** Александр Михайловичка, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы **Федотов** Семен Ильичка **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЛАРНЫ ЗАРЫГЫП КӨТӘЛӘР

Ватан хакына

Балтач егетләренең берсе гуманитар ярдәм илтеп кайтырга өлгерми, икенчесе юлга кузгала. Әнә шулай, аена икешәр мәртәбә барып, үз якташларын гына түгел, Татарстан егетләрен дә сөендерә алар.

Балтачта яшәүче Айдар Хисмәтуллин ай саен һәр егеткә туган яктан сәлам илтә, кирәк-ярак тапшыра. Өч бала үстерүче, 40 яшьлек Айдар үзе дә – Чечня сугышын кичкән кеше. Әнә шуңа да ул, махсус хәрби операция башлануга, үзенә нәрсә җитмәгән, шуны җыярга тотынган да инде. Үзе шулай ди.

– Миңа повестка килмәде. Шуңа күрә егетләргә моннан ярдәм итәргә булдым, – ди Айдар. – Иң элек бергә хезмәт иткән егетләргә дару алыйк дип хәбәр җибәрдем. Ул үтенечем тиз таралды. Берәү дә читтә калмады.

Ул Чечняда БТР йөрткән. Яшерми, үлем белән еш күзгә-күз очрашкан. Хәрби машина астында үзе сыярлык чокыр казып, шунда йоклаганнарын әле дә оныта алмый. Тауларда йөргән чаклары төшләренә дә керә. Исән калмам дигән чакларында догалар коткарган. Айдар авыр чакта гел Аллаһы Тәгаләгә сыенган. «Сугыш шундый нәрсә. Денсезне дә дингә кертә», – ди ул. Шуңа да Айдарга Ватанны саклаучы егетләр бик якын.

– Алар китте, без калдык. Егетләрне ташламаска кирәк. Мин инде андагы һәр шәһәрне, сукмакны яттан беләм. Шуңа да үзем барырга тырышам. Үз эшем дә кала. Әмма егетләргә кирәгрәк икәнемне аңлыйм да, акчаны дөньялар тынычлангач эшләрмен әле, дим. Исәнлек кирәк, – ди Айдар.

Аны анда Балтач егетләре генә түгел, башкалар да, Айдар абый килә, дип көтәләр икән.

– Бер барганда телефоннар эшләмәде. Алып килгән күчтәнәчләрне хәрби машинага бушаттык та, эчкәрәк кердем. Егетләрне эзлим. Барам да барам. Берзаман берәүдән безнекеләрне сорыйм. Ул миңа: «Абый, сез «передовой»да бит инде. Егетләр артыгызда», – ди. Борылып килүемә, якташлар каршы чыккан. Аптырашканнар иде. Миндә курку юк шул. Үземне гомер иткән кешегә саныйм. Гаиләм бар, өч балам үсә. Әнием дә, хатыным да борчыла инде. Төннәрен йокламыйлар. Гафу итсеннәр, әмма мин өйдә утыра алмыйм. Егетләр көтеп тора бит, – ди Айдар.

Һәр егетнең исем-фамилиясен белә ул. Егетләр янына килеп керүгә, «Балтачлылар, чыгыгыз», – дип кычкыралар икән.

– Мин анда үзебездән ничә егет икәнне беләм. Килдем, әйбер таратам. Окопларына кадәр кертәм. Күпме кычкырсам да, Арбордан Раушан дигән егет безнең янга чыкмый гына бит! Телефон номерын табып, моңа шалтыратам. Шунда бу: «И, Айдар абый. Минем әти дә, әни дә юк. Миңа кем әйбер җибәрсен…» – ди. Күңел тулды. Әмма күрсәтмәдем. «Егет, син – Балтачныкы. Моннан соң без килүгә чык», – дидем. Күчтәнәчне җитәрлек алып барабыз. Башка район егетләрен дә читтә калдырмыйбыз. Казан, Әлмәт шәһәрләреннән дә, тапшыр әле дип, посылка алып киләләр, – ди ул.

Айдар Нияз исемле егет янына әтисе Назыйх абыйны да алып барган. Дөресрәге, әтисе улына дип өйдәге «ГАЗель»ләрен илткән. Очрашу мизгелләре бигрәк күңелгә тиярлек булган. Ата улын кочаклап туя алмаган. Шунда Нияз әтисенә үзенә хат язган Миләүшәне күреп, сәлам әйтергә кушкан. Миләүшә Хәйруллина башлангыч сыйныфта укый икән. Нияз абыйсы Миләүшәнең хатын йөрәк янындагы кесәсендә йөртә. Җиңеп кайтуга, иң беренче эш итеп Миләүшәне күрәчәкмен, ди. Назыйх абый исә, кызчыкны күреп, кысып кочаклап, улына язган хаты өчен рәхмәтен әйтеп, шоколад биргән.

– Бердәм булу көч бирә. Без беренче көннән егетләргә ярдәм итәбез. Шулкадәр дус район икәнне аңладым. Егетләр исән-сау кайткач, Балтачның бер башыннан икенче башына кадәр өстәл корып, бәйрәм итәчәкбез. Сине түргә утыртабыз, диләр. Бирсен Ходай! Аларны өйдә зарыгып көтәләр, – ди Айдар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СУГЫШ ҺӘМ ТЫНЫЧЛЫК

Фикер

Украинада барган вакыйгалар уңаеннан халык арасында төрле фикерләр йөри. Махсус хәрби операциянең максатын һәркем аңлый, хуплый кебек, әмма кайчак: «Украинага үзебезгә бәреп кермәскә иде, алар безгә һөҗүм иткәч, пыр туздырып ташлаган булыр идек әле…» кебек сүзләр дә ишетергә туры килә. Күптән түгел дустым, фикердәшем, запастагы полковник Рөстәм Гомәров белән шул хакта сөйләшеп утырдык.

33 ел гомерен хәрби хезмәткә багышлаган якташымның бары тик үзе күргән-белгәннәрен генә сөйләргә, һәр вакыйганы үзенчә бәяләргә омтылуын белгәнгә, аның белән сөйләшү минем дә кайбер фикерләремне бераз анныклады, тәртипкә китерергә ярдәм итте. Мәсәлән, минем Россия тарихының шактый өлеше сугышлардан торуы турында язганым бар. Полковник Гомәров исә сугыш мәсьәләсенә икенчерәк караштa. «Россия бит күпчелек очракта үзенең иминлеген, бөтенлеген яклап сугышкан, үзеннән бик еракта колонияләр яулап алмаган, үзе кушылган яисә үзе кушкан халыкларга мөнәсәбәте дә бөтенләй башка булган аның», – диде. Сөйләгәннәренә дәлил итеп безнең тарихчылар әйткән саннарны китерде. XVI гасыр урталарыннан башлап Россия 75 сугышта катнашкан, шуның тугызын гына беренче булып үзе башлаган.

Кайбер халыклар яклау эзләп үзләре Россиягә мөрәҗәгать иткән. Кыскасы, полковник Гомәров Россиягә «агрессор» тамгасы сугудан ерак тора. Бу дөньяда бар халыклар гасырлар буе үзара сугышып яшәгән һәм яшәячәкләр дә әле. Бит, шагыйрь әйтмешли, «бу кешегә һәрчак нидер җитми».

Тарих сәхифәләрен актара-актара, без XX гасырга якынлаштык. Безнең өчен иң зур, иң канлы сугыш, әлбәттә, Бөек Ватан сугышы. Мин: «Бер генә дә тыныч яшәргә димәгән икән», – дип куям.

– Безгә тыныч яшәргә ирек бирмиләр, – ди әңгәмәдәшем, – без бихисап табигый байлыкларга ия, бу да кайбер дәүләтләрне ымсындырып торадыр. Бай, көчле Россия, әлбәттә инде, берәүгә дә баш иярга теләми.

– Бүгенге вазгыятьтә миңа Польшаның үз-үзен тотышы сәер кебек тоела. Совет чорында үзара дус яши идек кебек, – дим полковник Гомәровка.

– Кебек кенә шул. Польша җитәкчеләре Россияне 1612 елдан бирле кымтырыклап торалар. Заманында Россиянең, Украинаның, Балтыйк буе дәүләтләренең кайбер җирләре Польшага кергән. Инде күпме гасырлар узгач, Польшаның ерак тарихтагы вакыйгаларны искә төшереп, җае чыккан саен Россиягә ниндидер дәгъвалар белдереп яшәве сәер тоела. Инде бит Җир шарында җирләр күптән бүленгән, аерым дәүләтләр барлыкка килгән һәм һәр халык үз көнен үзе күреп яши. Польша Россия махсус хәрби операция башлагач, болганчык суда балык тотмакчы, янәсе, кайчандыр үзенеке саналган Украина җирләрен кире кайтармакчы була. Россияне таркату – аның күптәнге хыялы.

– Украина җирләрен алуда безне дә гаеплиләр бит.

– Моны тарихны белмәүчеләр яки белергә теләмәүчеләр әйтә. XVII гасырның беренче яртысына хәтле Украина Польша кул астында була. 1648 елда Польша изүенә чыдый алмыйча, Запорожье казаклары Богдан Хмельницкий җитәкчелегендә баш күтәрәләр һәм Россия составына керергә теләк белдерәләр. Богдан Хмельницкий үзе рус патшасына «прошение» яза. Казаклар баш күтәргән җирләрне Россиягә кертү озакка сузыла. Бары тик 1654 елда гына Переяславная Рада чакырылып, Украинаның бер өлеше Россиягә керүен игълан итә. Богдан Хмельницкий әнә шулай Украинаны Россиягә кушучы шәхес буларак тарихка кереп калган.

Без тарихны сөйләп чыгарга җыенмыйбыз. Рөстәм Гомәров элемтә техникумында студентларга Россия тарихы буенча лекцияләр укый, хәрби хезмәт дәресләре үткәрә.

Бүгенге сәясәтне тарих белән бәйләп аңлату бик ансат түгелдер. Чөнки тарихи вакыйгаларга төрлечә бәя бирү дәвам итә һәм кешене хак дөреслеккә ышандыру шактый кыен. Ә полковник Гомәров ышандыра белә. Соңгы ярты гасыр вакыйгаларының шактыенда ул үзе дә турыдан-туры катнашкан кеше. Ил җитәкчелеге җибәргән хаталар нәтиҗәсендә СССР дигән зур дәүләтнең ничек таркалуын да искә төшерде. «Бөек Ватан сугышыннан соң, 1955 елда «Варшава килешүе» оешмасы төзелеп, аңа җиңүчеләр ягыннан җиде ил кергән иде. Оешма озак еллар буе Европаны төрле тетрәнүләрдән саклап килде. Без 1987 елга хәтле чагыштырмача тыныч яшәдек», – ди әңгәмәдәшем. Килешү кысасында Европаның күп илләренә җиңүче якның гаскәрләре кертелде. Полковник Гомәров ул елларда Венгриядә хезмәт иткән. «Безгә басып алучылар итеп карамадылар. Венгрлар белән үзара ярдәмләшеп, дус яшәдек. Тик җитәкчелеккә Горбачев килгәч, ул тәкъдим иткән «яңача фикерләү» илне эчтән җимерә башлады. Михаил Сергеевич дөньядагы бөтен дәүләтләрнең үзара тыныч яшәячәгенә ышанды. «СССР берәүгә дә дошман түгел», – дип сөйләп йөрде, СССРга дошман дәүләтләр булырга мөмкинлеген уйлап карамады. Алкышлар астында Берлин стенасын җимерттерде. Ике ил бергә кушылгач, Германиядә ГДРның хокуклары бетте, фашизм яңадан баш калкыта башлады.

Европаның бөтен илләреннән Совет гаскәрләре чыгарылды, ә буш урынга НАТО гаскәрләре шыплап тулды. Армиябез тәмам таркалу чигенә килеп җитте. Ә Горбачев сәясәтен Ельцин дәвам итеп, гаскәрләр чыгаруны тагын да тизләтте. 1994 елда Украинадан соңгы ракета чыгарылды. «Күзне йомган килеш» базар икътисадына кергән булып, илдә җитештерүне туктаттык. Көнбатыш үзебезнекеләр кулы белән илне көчсезләндерде һәм аны бүлгәләү өчен шартлар тудырды. Кызганыч, без Россияне бөтенләй таркату буенча эзлекле сәясәт алып бардык.

– Украинада барган бүгенге вакыйгалар гасырлар буе дәвам иткән сәясәтнең чираттагы бер чылбыры дип кабул итеп буламы?

– Әлбәттә. Мин дөньяда барлык халыкларның үзара дус, тату яшәячәгенә, гомумән, ышанмыйм. «Тынычта яшисең килсә, сугышка әзерлән» дигән гыйбарәне Борынгы Римда ук туган дип укыганым бар, аны ниндидер хәрби язучы әйткән бугай. Менә шуннан тарихның гел сугышлардан торуына гаҗәпләнәсе юк.

Украинаның беркайчан да бүгенге кебек бәйле булганы юк иде, аның мөстәкыйль дәүләт булачагына өметем юк. Без исә, үзебезне яклап, махсус хәрби операция башладык. Үзебез башламасак, безгә барыбер бәреп керәчәкләр иде әле, чөнки моңа әзерлек 2014 елда гына түгел, бик күптәннән башланды һәм корылган мылтык кайчан да булса бер атарга тиеш иде.

Америка безнең күпмилләтле ил булуыбызны үз максатларында файдаланмакчы, ягъни төрле милләт халыкларын үзара чәкештереп бетермәкче.

– Рөстәм әфәнде, «сугыш» һәм «тынычлык» дигән сүзләр «мәхәббәт» һәм «нәфрәт» дигән сүзләр кебек янәшә йөри бит. Алар арасында чик тә юк, нибары бер адым ара гына кебек. Бу хәрби операция кайчан, ничек тәгәлләнер икән? Хәрби кеше буларак сезнең фараз нинди?

– Мин күрәзәлек итәргә яратмыйм. Сүз дә юк, һәр бәрелеш, һәр сугыш кайчан булса да килешү белән тәмамлана инде ул. Әмма килешү безнең файдага булсын өчен Россиянең һәрьяктан үсешкә ирешкән, халкының бердәм, ә армиянең көчле булуы кирәк. Илгә авырлык килгәндә, халык аерым бер идея, аерым бер шәхес тирәсенә туплана.

– Соңгы сорауны бирим инде. Чакыру килсә, бүген хәрби хезмәткә китәр идегезме?

– Әлбәттә. Мин – хәрби ант биргән кеше, ә Ватанны саклау – изге бурычым. Ватан, ана кебек үк, бер генә ул һәм аны сайлап алмыйлар. Дөрес, 64 яшьлек полковникны армиягә алмаслар инде. Чөнки, без хезмәт иткән чорныкы белән чагыштырганда, бүгенге полковник вазыйфалары икенчерәк, бераз укытсалар гына инде.

– Иптәш полковник, сезне якынлашып килүче бәйрәм – «Ватан сакчылары көне» белән!

– Иртәрәк булса да, мин дә сезнең укучыларга бәйрәм котлаулары юллый торыйм әле. Бер сүзем калган икән. Беләсезме, иң тыныч халык – хәрбиләр бит ул! Чөнки без сугышның нинди зур афәт икәнен башкалардан күбрәк сиземлибез, күбрәк беләбез. Шуңа күрә дөньялар тыныч булсын!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Аттестат о среднем общем образовании № 01618001841332, выданный на имя Эль-Шейкх Имран Хуссамовича «Лицей-интернатом №7» Ново-Савиновского района г. Казани РТ 27 июня 2022 года, считать недействительным в связи с утерей.

Студенческий билет №648 на имя студента 1 курса РАНХИГС Мавлонова Чингиза Алишеровича, выданный в 2021 году, считать недействительным в связи с утерей.

Язучы фикере

Меломан

Музыка ярата торган кешеләр була. Хәер, аны барыбыз да яратабыздыр инде. Бишек җырын тыңлап, теле ачылган, тәпи баскан кешеләр бит инде. Авылда туганнар әле төнге урам буйлап җырлап та йөргәндер. Яшь чак бит. Күңелле иде ул чаклар. Әле авылга кайткач та, кайвакыт шул чорларны искә төшереп, дуслар белән урам әйләнгән бар. Үзебезгә күңелле була. Тик әби-бабайлар гына бармак янап кала.

Казан буйлап фатир снимайт итеп йөргән чорда мин дә бер шундый күршегә юлыктым. Музыка ярата торган. Мин дә вакыты-вакыты белән акыртып алам инде аны. Наушник белән дә тыңлаштырам. Тик бу күршенең сәер бер үзенчәлеге бар. Музыканы бу төнлә ярата. Төнге сәгать унике җитүе була, бөтен көченә музыка акыра башлый. Бер җыр ул. Чит илнеке. Сүзләре дә, көе дә таныш түгел. Тик тавышы юка гына стенаны бар дип тә белми. Үлеп ятсаң да торып утырырлык итә.

Беренче көнне түздем инде мин. Икенче төнне дә түздем, тик башка әллә нинди уйлар керә башлады. Нигә төнлә куя икән моны, дим. Бер җыр инде ул. Туктый да кабат башлана. Бераз тора да тагын дәвам итә. Башта әллә ирнең төнге эшләренә шул музыка ярдәм итә микән, дип уйладым. Шуңа түздем, чыгып, ишек шакырга кыюлыгым җитмәде. Булмый да бит инде алай. Аның ишеген шакып: «Күрше, зинһар өчен, виаграңны сүндер әле, йокларга комачаулый», – дип әйтәсеңмени? Төн буе шулай дәвам иткәч, бу уйдан да кире кайттым. Төн буе сөйрәп кабызырга полуторка машинасы түгел бит инде. Сәбәбе башка нәрсәдәдер, дим. Кычкырыша торган булсалар да, һич югы берәр көн ял итәрләр иде. Ни сәбәпле кычкырышсалар да. Хәтта сугышсалар да. Кыскасы, мин ни уйларга да белмәдем.

Дүрт-биш төн йокламый чыккач, түзмәдем, иртән күршеләрнең ишеген шакыдым. Озак шакыдым. Ишек ачучы булмады. Кемдер яши бит инде монда. Гаеп үземдә түгелдер ич инде, берәр психик авыру эләктермәгәнмендер? Берничә көн ишек кагып та, ачучы булмагач, дөнья хәлен белеп булмый дип, табибка да күренеп кайттым. Чир-фәлән тапмадылар.

Адәм баласы бөтен нәрсәгә дә күнегә. Тора-бара мин дә артык игътибар бирми башладым. Шулай да әлеге хәлнең сәбәбен белергә теләү басылмады. Ишек ачучы да булмады. Шуннан бу фатирда кем яшәгәнен белешергә тотындым. Ә бәлки, анда кеше яшәмидер. Җеннәр оялагандыр. Шуңа күрә төннән таңга кадәр пәри туе үткәрәләрдер. Алай булып чыкмады. Эзли торгач, мин монда кем яшәгәнен ачыкладым, аның улы да бар икән. Улының телефон номеры да бар икән. Кыскасы, музыкаль бәладән котылуга юл ачылган кебек булды.

Улы белән очрашкач, барысын да аңлатып бирдем. Ә ул һушы китеп тыңлап торды да тел шартлатып куйды.

– Яп-яланаяк! – диде аннан соң. – Мин бит заманча магнитофон сатып алган идем. Таймер белән эшли ул. Бераз булдым да иртәгә кереп алырмын әле дип, шул килеш калдырып киттем. Аннан соң онытыла төшкән инде.

Мин нәрсәдер аңлаган кебек булдым. Музыка уйната торган бик яхшы аппарат сатып алган да әтисенә калдырып киткән бу. Таймерны төп-төгәл сәгать уникегә куйган. Төнге уникегә…

– Ләкин әти-әниең…

– Әни юк инде хәзер. Ә әти… Колагы ишетми аның. Берни дә ишетми.

Менә барысы да урынына утырган кебек булды. Колагы ишетмәгәч, теге магнитофонның акырганын да, минем ишек какканны да ишетмәгән инде. Беркемне дә гаепләп булмый. Берни дә әйтеп булмый. Хәер…

Ялгыз яшәгән әти-әниегезнең хәлен белешергә онытмагыз. Атнасына бер тапкыр булса да.

Марат КӘБИРОВ

Реклама 6+

«Иртәнге чәй»ләр сезне кунакка дәшә! Яраткан җырларыгызны тыңлап, кушылып җырлап, рәхәтләнеп сөйләшеп, безнең белән бергә кич утырырга чакырабыз. Сез яраткан артистлар, яшь популяр җырчылар – барысы да бер сәхнәдә. Күңелләрне җылытып, карларны эретерлек концерт булачак.

АШИНА КОТКАРЫРМЫ?

Премьера

Караганнан соң битне салкын су белән юасы килгән спектакльләр була. «Ашина» әнә шундыйлардан. Тинчурин театрында Ркаил Зәйдулланың пьесасын режиссер Илсур Казакбаев сәхнәләштерде.

«Татар-информ»

Спектакльнең жанры мистик драма дип билгеләнгән. Төркиләрнең риваятьләре буенча, Ашина – әнисе үлгән малайны имезеп үстереп, нәселне, ыруны коткарган ана бүре. Вакыйгалар узган гасырның 50 нче еллары ахырында тиздән су астында калачак утрауда бара. Печән җыярга килгән геройлар арасындагы мөнәсәбәтләр шактый катлаулы. Алар еллар буе үзләренең хисләрен күңелнең тирән чоңгылларына яшереп, ә кайберләре көнчелек һәм мәкерлекләрен күрсәтми яши. Рольләрне Гөлназ Нәүмәтова, Зөлфәт Закиров, Әдилә Хәсәнова, Айсылу Мөсәлләмова, Резедә Сәләхова, Салават Хәбибуллин, Илфак Хафизов, Айзат Закиров башкара.

Бер-бер артлы сөйләнгән монологлар аша геройларның күңел дөньясы ачыла бара. Җавапсыз мәхәббәт, балачакта кичергән авырлыклар, югалтулар… Аларның һәрберсенә зур тетрәнүләр, фаҗига аша үтәргә туры килә. Актерларның ничек итеп геройларның хис-кичерешләрен, авыр һәм үзгәрүчән характерын, кәефен шуның кадәр тирән, һәр күңелгә үтеп керерлек итеп җиткерүләре сокланырлык.

Декорацияләр гади генә булса да, алар бик оста һәм гармониядә оештырылган. Эссе көн турында сүз баруына карамастан, геройларның итек, бишмәт, бүрек һәм итекләрдән булуы сискәндерә. Моның тоткынлыкка ишарә булуын тамашачы бераз соңрак аңлый.

Әсәрнең фәлсәфи өлеше Ибраһимның (Зөлфәт Закиров) гарип улында ачыла. Мирза (Әдилә Хәсәнова) образы тетрәндергеч. Ул кешенең кылган гөнаһлары өчен сынау да, кычкырып әйтә алмаган фикерне халыкка җиткерү дә кебек. Әйтергә кирәк, Әдилә Хәсәнова авыру малайны сөйләмендә һәм һәр хәрәкәтендә бик оста күрсәтә.

Спектакльдә ана бүре өзгәләнүе күңелгә шом сала. Су тавышы, бүре улавы – болар су басу турындагы гади кисәтү генә түгел, ә милләткә янаган куркыныч. Кеше – һәрвакыт сайлау алдында, әмма һәр кылган гамәленең алдында кайчан да булса барыбер җавап тотасы. Чор сәясәтен геройлар төрлечә кабул итсәләр дә, алар барысы да – система корбаннары. «Ашина»да хакимияткә булган мөнәсәбәт, нәселне саклап кала торган риваятьләр көче, яшәү мәгънәсе – барысын да тоемларга була. Спектакльнең төп фикере Ашина (Гөлназ Нәүмәтова) монологында яңгырый: «Явызлык ул үзеннән-үзе арта. Ә ярату көч таләп итә». Гади, әмма шул ук вакытта гаять зур мәгънә сыйган сүзләр. Халык риваятьләре белән сугарылган вакыйгалар трагик финалга китерә – утрау да, андагы кешеләр дә су астында кала.

Шагыйрә, язучы Илсөяр Иксанова бу спектакльдә һәр кеше үзенең фәлсәфәсен таба дигән фикердә:

– Әлеге спектакльне мин, һичшиксез, Тинчурин театрының зур уңышы дип саныйм. Соңгы вакытта караган спектакльләр арасында бу миңа иң нык тәэсир иткәне, дулкынландырганы һәм уйландырганы булды. Анда бик кыска гына вакыт арасында шундый зур, тыгыз материал салынган. Тамашачының күпчелеге кабул итте дип уйлыйм. Монда һәр кешегә уйланырлык урын бар. Спектакль бер кешене дә битараф калдырмады. Иң мөһиме шул, – диде Илсөяр Ихсанова. – Әлбәттә, әсәр бик тирән. Аны кабат-кабат кайтып, уйланып, анализларга кирәк. Чөнки монда һәр хәрәкәткә, һәр персонажга зур фәлсәфи фикер салынган. Әсәрнең төп фикере – ярату. Дөньяны ярату гына коткара ала, дигән гыйбарә бар. Коткара ала, ләкин ярату бик авыр. Ярату өчен кешенең үзенең камил булуы кирәк. Камил кеше генә ярата ала. Образларның һәркайсында шундый зур йөк. Алар берсе дә ак һәм кара гына түгел. Дөньяда кеше ак яки кара гына була алмый. Алар бөтенесе дә – система корбаннары. Бу бик ачык күрсәтелә. Спектакльдәге гарип баланың: «Безне Ашина коткарачак», – дип бертуктаусыз кабатлап йөрүе – өмет, бик тирән фәлсәфә. Режиссерның табышлары бик күп. Көтелмәгән, һәр хәрәкәтендә ниндидер фәлсәфи, фикер таба торган ачышлары бар. «Ашина» – бүгенге тормышыбыз, кешелекнең яшәеше турында бик тирән фикерләр уята торган спектакль. Уйландыра, тетрәндерә һәм һәркемне үзенең эчендә казынырга һәм киләчәккә ничек барырга дигән сорауга җавап эзләргә мәҗбүр итә.

Язучы һәм драматург Хәбир Ибраһимов «Ашина»ны фестиваль спектакле буларак, бүген бик кирәкле әсәр дип саный.

– Бүген бу әсәр бик кирәкле дип уйлыйм. Безнең тарих гел әйләнеп, кабатланып тора. Мондый вакыйгалар кайтмасын иде инде. Бу – Сталин вакытындагы репрессияләрне, коточкыч, золым вакытларын сурәтләгән әсәр. Әйе, ул халык ыжгырып йөри торган касса спектакле түгел. Әмма анда тирән фәлсәфи төшенчә ята. Ашина – ана бүре. Ул әсәргә риваять керткән. Монда ана бүре трагедиясе дә, гади халыкның да, гарип малайның трагедиясе дә бирелә, – ди язучы. – Мистика да бар. Ибраһимның малае: «Ашинаны күрсәм, тереләчәкмен», – ди. Һәм соңыннан чынлап та могҗиза була: Мирза терелә, аякка баса. Димәк, Ашина илаһи бер көчкә ия дип тә аңлыйбыз. Режиссерның эше бик ошады. Бу әсәрне башкача куеп та булмый торгандыр. Бу әсәр көнкүрештә ничек бар – шулай эшләнгән булса, ул, бәлки, алай ук отышлы булмаган булыр иде. Символика аша режиссер аның фәлсәфи төшенчәсен, тирәнлеген катлауландырып җибәргән һәм авторның әйтәсе килгән сүзен тамашачыга җиткергән. Артистларның уены да сокланырлык. Уйнау өчен җиңел әсәр түгел бу. Һәрбер сүз, һәрбер хәрәкәт, һәрбер эпизод пластикага корылган. Пластика аша да әсәрнең мәгънәсен тамашачыга җиткерергә тырышкан. «Ашина» – бик көчле спектакль. Мин аны төрле фестивальләрдә катнашып, урыннар яулар, дип тә уйлыйм.

Ләйсән САФИНА

НӘНИЛӘР «ОСКАР»Ы

«БАЛАЛАР ПРЕМИЯСЕ» ЛАУРЕАТЛАРЫ БИЛГЕЛЕ

Кызыл келәм, затлы сыннар, популяр җырчылар һәм нәни артистлар. Казанда «ТМТV»ның «Балалар премиясе»н тапшыру тантанасы әнә шулай купшы узды. Ул тагын нәрсәләр белән шаккатырды? 4 сәгатькә якын барган тамашаны без дә карап кайттык.

«Татар-информ»

Өченче тапкыр үткәрелә торган «Балалар премиясе» күп кенә нәни йолдызчыкларны кабызырга өлгерде. Бу гади концерт кына түгел. Ул – яшь талантлар арасында уздырылучы беренче музыкаль-телевизион премия, иң-иңнәрне бүләкләү тантанасы. Биредә 16 яшькә кадәр җырчылар, инструменталь, хореографик коллективлар бүләкләнә. Алар – атна саен «ТМТV» телеканалында бара торган «Балалы солянка» тапшыруы җиңүчеләре. Татар җырларын, биюләрен, уен коралларында татар халык көйләрен башкарган балалар лауреат булыр өчен көч сынашкан. Нәни йолдызларның күбесе, әле яшь булуларына карамастан, зур сәхнәләрдә чыгыш ясап чыныккан, халыкара, Россия, Татарстан күләмендә узган бәйгеләр лауреатлары, гүзәллек һәм спорт конкурсларында җиңү яулаган малайлар-кызлар.

Тантананың үзенә күчик. Монда балаларга үзләрен чын йолдыз кебек хис итәр өчен барлык шартлар да тудырылган иде. Лауреатлар сәхнәгә әти-әниләре, вокал укытучылары, остазлары белән кызыл келәмнән узды, кыйммәтле статуэтка, диплом белән бүләкләнде, ә аннан соң танылган җырчылар белән бер сәхнәдә чыгыш ясады.

«ТМТV» телеканалы директоры Лилия Кадыйрова проектның туган телдә булуы балалар өчен әһәмиятле дип саный.

– Балаларны татар телен буыннан буынга тапшыручы, татар җырын, телне популярлаштыручы итеп күрәсебез килә. Әти-әниләргә, әби-бабайлар, остазларга аерым рәхмәт. Чөнки туган телгә, үзебезнең татар җырына мәхәббәтне алар тәрбияли, – диде ул.

«Балалар премиясе» лауреатлары: Наилә Славина, Ләйлә Таишева, Аслан Миргаязов, «Казан» бию ансамбле, Айсәль, Азалия Гыйләҗева, Амелия Фәтхиева, Әминә Сабирова, Әминә һәм Мәдинә Рәсуловалар, Ясминә Гарипова, Алия Төхвәтуллина, «Тодес» бию ансамбле, Милина Хәйруллина, Зилә Шабаева, «Little Stars» төркеме, Самир Гобәйдуллин, Раяна Мэйджик, Айза Галиева.

«Балалар премиясе»н, елдагыча, Рамил Шәрәпов алып барды. Аның ярдәмчеләре Наилә Славина, Аслан Миргаязов һәм Ләйлә Таишева иде. Нәни йолдызлар Аслан Миргаязов белән Ләйлә Таишева тандемы күпләрнең күңеленә хуш килгәндер. Матур итеп җырлаулары белән генә түгел, ә үткен телле, юмор хисле алып баручы буларак та сокландырды алар. Наилә Славина – Эльмира Кәлимуллина, Самир Гобәйдуллин – Ришат Фазлыйәхмәтов, Алия Төхвәтуллина – Азат Фазлыев, Зилә Шабаева – Эльмир Низамов, Айза – Айдар Галимов дуэтлары аеруча истә калырлык булды.

Кызыл келәмнән кызы Айза белән үткән Люция Галиева мондый бәйрәмнәр кирәк дигән фикердә:

– Бу бәйрәмне ел саен көтеп алабыз. Айза беренче елда үзе генә җырлаган иде, җырчылар белән чыгыш ясаячагын белгәч, булдыра алырмын микән, дип борчылды. Узган ел Рифат Зарипов белән җырлады. Быел Айдар Галимов белән чыгыш ясау бәхете елмайды. Без әле дә шок хәлендә, моны көтмәгән идек. Айдар абыйсы белән җырлау Айзаның хыялы иде. Алар бер-берсенә туры килә. Икесе дә тыныч, сәхнәдә елмаеп торалар. Айдар абый балада өмет уята белә. Без аңа бик рәхмәтле. Монда очраклы балалар эләкми, һәрберсе талантлы. Алар арасында бернинди көндәшлек юк, бер-берсе өчен сөенәләр, – диде ул.

Музыкаль премиянең тагын бер үзенчәлеге: җырчылар талантлы яшь башкаручылар белән генә түгел, үзләренең балалары белән дә чыгыш ясый. Мондый самими чыгышлар тамашачы күңелендә аеруча истә калгандыр. Җырчы гаиләләре үзенчәлекле чыгышлар әзерләп, балаларының да төрле талантларын күрсәттеләр. Әйтик, Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова уллары өчесе өч төрле уен коралында уйнап, тамашачыны таң калдырды. «Балалар премиясе» сәхнәсендә шулай ук кызы Таңсылу белән Ләйсән Гыймаева, әтисе Фәрит Таишев белән Ләйлә Таишева, уллары белән Рената Тэй, Эльвира Хамматова, кызы Диана белән Илнат Фәрхуллин, әнисе белән Чулпан Йосыпова, гаиләләре белән Рәфинә Ганиуллина һәм Рәзил Камалов, Гөлназ һәм Илсур Шәрипҗановлар чыгыш ясады.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 226

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+